**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Олы Кариле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

14 нче декабрь 2019 ел № 3

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 нчы елның 26 нче ноябрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясе, Олы Кариле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру: торак пункт эчендә (җәйге-көзге чорда) чүп үләннәрен чабу;
- Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру;
- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру;
- Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын оештыру;».

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 285 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 119 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 119 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 285 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 154 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 154 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге составына керүче Олы Кариле авылы халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясе, Олы Кариле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру: торак пункт эчендә (җәйге-көзге чорда) чүп үләннәрен чабу;
- Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру;
- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру;
- Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын оештыру;» соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга .

3. 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясе, Чаллы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

-Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру;
- Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру;
- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру;
- Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын оештыру.

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер урамы, 1;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин урамы, 43;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Keче Кариле авылы, Вахитов урамы, 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Кариле авыл җирлеге
башлыгы: Ф.Г. Гарифуллин